

Татарлар Мордовиядә рәхәтләнеп яши: белем ала, эшли, иҗат итә...Регионыбыз Ислам мәдәни vзәге белән «Мордовия моселман яшьләре берлеге» активы бергә-бергә бик кvп чаралар vткәрәләр. Берничәсе турында.
Мәсәлән, 30 январьда, Мордовия Республикасы Мәгариф министрлыгы һәм Ислам мәдәни vзәге арасында хезмәттәшлек турында килешv кысаларында, Ислам мәдәни vзәге хезмәткәрләре, директоры Фагим хәзрәт Шафиев һәм «Мордовия моселман яшьләре берлеге» активы белән берлектә, Ромоданово районы Белозерье урта мәктәбендә булдылар.
«Россия традицион рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләре» темасын ачып, Ислам мәдәни vзәге директоры урынбасары, РМ Иҗтимагый палатасынын Комиссия рәисе Надия Низаметдин кызы Азисова укучыларга Россиянен традицион рухи-әхлак кыйммәтләрен саклау һәм ныгытунын моһимлеге турында сойләде.      Бvгенге чынбарлыкта Ватанга мәхәббәт, Ватанга хезмәт итv, югары әхлакый идеаллар, нык гаилә, vзара ярдәм һәм vзара хормәт, тарихи хәтер һәм буыннар дәвамчанлыгы, Россия халыкларынын бердәмлеге кебек кыйммәтләр аеруча моһим булып тора. Балалар белән бергә Ватан, халык, гаилә, туганнар сvзләренен килеп чыгышын да белделәр.
Фагим хәзрәт Шафиев vз чыгышында белем алу, пәйгамбәрләр тормышыннан мисаллар китереп vз-vзенне даими камилләштерv, җәмгыятькә һәм гаиләгә файдалы булыр очен, мәгънәле тормышка омтылу кирәклегенә басым ясады. Шул ук вакытта, ул гомумроссия гражданлык һәм милли тәнгәллекне, шулай ук әхлакый нигезләрне, тарихи хәтерне һәм буыннар дәвамчанлыгын формалаштырунын моһимлеген ассызыклады.
Динара Няиль кызы Шабаева, Ислам мәдәни vзәге психологы, «Мордовия моселман яшьләре берлеге» житәкчесе, укучылар белән «Кайда логика?» һәм «Бәлеш» мәдәни-милли клубнын эшчәнлеге белән таныштырды.
Укучылар зур кызыксыну белән тәгъдим ителгән уеннарны уйнадылар, милли фольклор персонажларын, татар халкынын фразеологизмнарын, милли, дини бәйрәмнәрне, кинproblem ребусларны, заманча әсәрләрне һәм театральләштерелгән тамашаларны чиштеләр. Ин актив балаларны Үзәк мәйдан-чыгында узачак «Бәлеш» һәм инициативалы «Беренчеләр хәрәкәте» белән очрашуга чакырдылар. Гадәттәгечә, очрашу ахырында мәктәпкә һәм укучыларга бvләкләр тапшырыла: танып белv уеннары, татар теле һәм әдәбияты буенча фәнни, методик һәм уку әдәбияты.
Дәрес тәмамланганнан сон мәктәп директоры Эльвира Искәндәр кызы Киреева «Үсеш ноктасы», «Робототехника» белем бирv мохитендә унышлы гамәлгә ашырыла торган проектларга игътибарны юнәлтеп, мәктәп буенча экскурсия vткәрде. Анда татар халкынын тормыш - конкvрешен, мәдәниятен һәм тормыш рәвешен чагылдыручы экспонатлар, шулай ук Герой партасы (Равиль Касыйм улы Кудряев) саклана.
Укучылар белән очрашулардан сон унай энергия белән тукланасын һәм «Моһим нәрсәләр турында сойләшvләр» vткәрvнен актуальлеген анлыйсын. Бу vсеп килvче буын очен генә тvгел, бу буыннар чылбырын озмәс очен, боек Россиянен традицион кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту максатыннан безнен белем һәм тәҗрибәбезне житкерv очен моһим.

Бер атна элек тагы бер очрашv: хезмәттәшлек турында килешv кысаларында, Ислам мәдәни vзәге хезмәт-кәрләре һәм «Мордовия Моселман яшьләре берлеге» активы Мордовиянен Рузаевка районы Татар Пешлә урта гомуми белем бирv мәктәбе» ндә булдылар.



Мордовия Республикасында рухи-әхлакый vсеш класслары булган 6 «Пилот мәктәп» булдырылган, аларнын берсе биредә; анын партнеры булып Ислам мәдәни vзәге һәм Мордовия моселманнарынын Үзәк Диния нәзарәте тора. Алар арасында жылы, дустанә монәсәбәтләр жайга салынган. Мәктәп укучылары Ислам мәдәни vзәгенә экскурсиягә киләләр, Үзәк vткәрә торган конкурсларда һәм викториналарда катнашалар, ә педагогик коллектив конференцияләр, тvгәрәк остәлләр һәм башка чаралар эшендә катнаша.
Кунакка, традиция буенча, Үзәк хезмәткәрләре буш кул белән килмәгән, татар теле һәм әдәбияты буенча кvп санлы әдәбият, шулай ук сыйныфтан тыш эшләр очен кулланмалар һәм китаплар алып килгәннәр.
Надия Низаметдин кызы Азисова балаларга Ислам мәдәни vзәге һәм башка татар ижтимагый оешмалар эшчәнлеге турында сойләде, балаларга традицион кыймматләрне саклау, туган мәдәниятне, гореф-гадәтләрне белv, Ватанынны ярату һәм торле агымнарга каршы тору никадәр моһим икәнен кvрсәтте. Шулай ук яшьләрнен «Беренчеләр хәрәкәтендә» («Движение Первых») катнашу кирәклеге турында әйтте. Ин актив балаларны Үзәк мәйданчыгында узачак «Бәләш» белән очрашуга чакырды.
Динара Няиль кызы Шабаева укучылар белән «Минем мәдәниятем - минем мирас» интеллектуаль уены vткәрде. Танылган язучылар һәм шагыйрьләр, кvренекле галимнәр һәм рухи лидерлар исемнәрен, татар ризыклары һәм милли кием элементлары атамаларын, милли һәм дини бәйрәмнәрне искә тошереп, укучылар илһамланып уеннар уйнадылар.
Ә 25 январьда, яшь буынга рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирv эшчәнлеге кысаларында, Ләмберә районынын Аксёново урта гомуми белем бирv мәктәбе очраштылар.
Очрашу барышында РНКАТ РМ «Якташлар» жәмгыятчелеге белән Ислам мәдәни vзәге житәкчелегеннән мәктәп директорынын тәрбия буенча кинәшчесе Рушания Низаметдин кызы Шамшетдиновага мәктәп очен методик кулланмалар, китаплар, остәл уеннары, дәреслекләр, журналлар һәм укучылар арасында дәрестән тыш ижади эшчәнлек оештыру очен плакатлар тапшырылдылар.
Шулай ук олкән сыйныф укучылары белән « Россия халыклары мәдәнияте һәм традицияләре» дигән интеллектуаль уен-квиз vткәрелделәр. Нәтижәдә, ин кvп балл жыйган команда татлы призлар белән бvләкләнде.
Мондый очрашулар кvпмилләтле Рос-сия халыкларынын мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен ойрәнvгә кызыксынуны арттырырга ярдәм итә, бу этникара монәсәбәтләрнен гармонияләшvенә һәм Ватанга мәхәббәт хисен тәрбия-ләвдә унай йогынты ясый.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**